# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Урта Тигәнәле авылы

12 ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Урта Тигәнәле торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Урта Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- урам утларын карап тоту;
- җирләү урыннарын төзекләндерү..

3. Әлеге карарны Урта Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Урта Тигәнәле мәдәният йортында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Э.М.Камалова